Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

28 август 2020 ел №399

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2019 елның 26 июлендәге 300 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә яки бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында аларның коллегиаль идарә органнары составына түләүсез нигездә катнашуга (сәяси партиядән һәм һөнәри берлек органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасыннан тыш) эш бирүче вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында нигезләмә хакында»гы карары үз көчен югалткан дип тану турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларын камилләштерү максатларында коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Әлмәт мунуиципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2019 елның 26 июлендәге 300 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә яки бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында аларның коллегиаль идарә органнары составына түләүсез нигездә катнашуга (сәяси партиядән һәм һөнәри берлек органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасыннан тыш) эш бирүче вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында нигезләмә хакында»гы карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник», газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны районның законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Баһманов И.Р.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов